ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОКАКЕРЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Улица Советская, дом 51,
село Старые Какерли, 422476

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ
КӘКЕРЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет урамы, 51нче йорт,
Иске Кәкерле авылы, 422476

Тел.: (84375) 3-01-35 факс: (84375) 3-02-35, e-mail: Skaker.Drz@tatar.ru,

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

07 февралның 2020 ел № 3

Татарстан Республикасы Чүпрәле
муниципаль районы Иске Кәкерле
авыл җирлеге башкарма комитетына
гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә
анализ үткәрү тәртибе турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ, «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 02.05.2006 ел, №59-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Кәкерле авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Кәкерле авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибен раслау (1 нче кушымта).

2. Әлеге карарны Иске Кәкерле авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында, Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында, авыл җирлеге бүлегендә һәм түбәндәге адрес буенча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы Иске Кәкерле
авыл җирлеге башлыгы: С.А.Хусаинов

Чүпрәле муниципаль районы Иске
Кәкерле авыл җирлеге Башкарма
комитетының
07 февралнең 2020 ел. № 3 Карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Кәкерле авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибе.

1. Әлеге Тәртип «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясын үтәү йөзеннән эшләнде һәм Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Кәкерле авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләрен гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Кәкерле авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына кергән гражданнар мөрәҗәгатьләренә анализ ясау гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау буенча эшнең сыйфатын күтәрү, гражданнарның иҗтимагый фикерен һәм актуаль проблемаларын өйрәнү, шулай ук гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү рәвешләрен һәм методларын камилләштерү, аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау сыйфатын күтәрү максатларында үткәрелә.

3. Тиешле чорда гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ гражданнарның барлык мөрәҗәгатьләре, шул исәптән язма рәвештә, электрон документ формасында, Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылган Интернет-кабул итү юлы белән, шулай ук вәкаләтле затлар тарафыннан гражданнарны шәхси кабул итү барышында кабул ителгән мөрәҗәгатьләр буенча гамәлгә ашырыла.

4. Кергән мөрәҗәгатьләргә Анализ ел саен башкарыла.

5. Гражданнарның мөрәҗәгатьләренә анализ үткәрү нәтиҗәләре буенча Башкарма комитет сәркатибе хисап чорыннан соң килгән айның 10 числосына кадәр аналитик белешмә төзи.

6. Аналитик белешмәдә шәхси кабул итүдә кабул ителгән гражданнар саны, гражданнарны шәхси кабул итү һәм шәхси күчмә кабул итү буенча вәкаләтле затлар турында, мөрәҗәгатьләрнең тематикасы турында, мөрәҗәгатьләр нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар турында, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый һәм башка актлар турында мәгълүмат булырга тиеш.

7. Җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә тиешле вакыт эчендә Анализ узган елның шул ук чорында кергән гражданнар мөрәҗәгатьләре белән чагыштыру юлы белән үткәрелә.

8. Башкарма комитет секретаре ел саен аналитик белешмәне Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында «Гражданнар мөрәҗәгатьләре» бүлегендә хисап чорыннан соң килүче айның 15 числосына кадәр урнаштыруны тәэмин итә.